5.8.1. – Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Хабибрахманова Р.Н. Һөнәри белем бирүче уку йортларында «Туган телдә әдәбият» укытуда интерактив технологияләр куллану // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2025. № 3 (26). URL: https://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2025/09/2025_3_habibrahmanova.pdf

УДК 37.01

**Резеда Накифовна Хабибрахманова**
Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, һөнәри белем бирү бүлеге фәнни хезмәткәре

# Һөнәри белем бирүче уку йортларында «Туган телдә әдәбият» укытуда интерактив технологияләр куллану

***Аннотация:*** Мәкаләдә урта һөнәри белем бирүче уку йортларында «Туган телдә әдәбият» укытуда интерактив ысуллар куллануның нәтиҗәлелеге карала. Интерактив укытуның асылы, аның педагогик кыйммәте һәм белем бирү процессына йогынтысы анализлана.
***Төп сүзләр:*** һөнәри белем, технология, интерактив технология, уку-укыту, студент, укытучы, дәрес, әдәбият, әсәр, анализ, мотивация, тәнкыйди фикерләү, мөстәкыйльлек, эшчәнлек

**Rezeda N. Khabibrakhmanova**
Researcher, Vocational Education Development Department, Institute for the Development of Education of the Republic of Tatarstan, Kazan, Russia

# The Use of Interactive Technologies in Teaching “Literature In The Native Language” in Educational Institutions of Vocational Education

***Abstract:*** The article examines the effectiveness of using interactive methods of teaching “Literature in the native language” in educational institutions of secondary vocational education. The article analyzes the essence of interactive learning, its pedagogical value and impact on the educational process.
***Keywords:*** vocational education, technology, interactive technologies, learning, student, teacher, lesson, literature, work, analysis, motivation, critical thinking, independence, activity

Хәзерге заман белем бирү процессы студентларны укыту эшчәнлегенә актив җәлеп итүгә юнәлтелгән яңа алымнар таләп итә. Шуңа да, бүгенге көндә белем бирү процессын динамик, кызыклы һәм продуктив итәргә мөмкинлек бирә торган интерактив укыту методлары аеруча әһәмияткә ия.

Интерактив технологияләр кулланып укыту белем бирү процессында катнашучыларның актив хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән, студентларда мөстәкыйль тәнкыйди фикерләү формалаштыруга, мәгълүматны анализлый белү, үз позицияңне дәлилләү, коммуникатив сәләтләрне үстерергә ярдәм итә.

Интерактив укыту – укытучы һәм студентның диалогка нигезләнгән үзара хезмәттәшлегенең катлаулы процессы. Белем бирүнең интерактив ысуллары бик нәтиҗәле, чөнки алар укытуның югары дәрәҗәдә мотивациясенә, максималь индивидуальлегенә ярдәм итә, иҗади мөмкинлекләрен ача.

Интерактив укытуның төп характеристикасы – белем бирү процессында студентларның актив позициясе; белем бирүдә катнашучылар арасында үзара хезмәттәшлек;

© Хабибрахманова Р.Н., 2025

белемнәрнең проблемалы һәм тикшеренү характеры; тәнкыйди фикерләү һәм иҗади потенциал үсешенә йөз тоту.

*Interactive learning* (ингл.) термины укытуны, аңа нигезләнгән укыту субъекты (алып баручы, укытучы, тренер, җитәкче) белән актив хезмәттәшлекне белдерә. Г.К. Селевко фикеренчә, интерактив укыту — субъектларның һәм белем бирү объектларының үзара бәйләнешен яхшы оештырып, алар арасында ике яклы мәгълүмат алмашып укыту ул [1, с. 239].

Урта һөнәри белем бирүче уку йортларында «Туган телдә әдәбият» дәресләрен укытканда интерактив технологияләр куллану аеруча актуаль, чөнки бу дисциплиналар теоретик материалны үзләштерүне генә түгел, бәлки аның сөйләм эшчәнлеге процессында актив кулланылуын, текстларны анализлауны, грамоталы язу һәм телдән сөйләм формалаштыруны да таләп итә.

Әдәбият дәресләрендә интерактив технологияләр кулланып эшләү фәнгә кызыксыну һәм мотивация дәрәҗәсен арттырырга, студентларның коммуникатив күнекмәләрен үстерергә, мәгълүматны мөстәкыйль анализлауга тәнкыйди фикерләвен һәм сәләтен формалаштырырга, студентларны белем бирү процессына актив җәлеп итү исәбенә белемнәрне үзләштерү сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә.

Әдәбият укыту студентларда белем генә түгел, сөйләм күнекмәләрен дә формалаштыруны, әдәби текстларны анализлау, әдәби әсәрләрне интерпретацияләүне, үз карашыңны дәлилләүне таләп итә. Интерактив ысуллар әлеге бурычларны хәл итүгә, студентларга актив хезмәттәшлек процессында материалны үзләштерергә дә ярдәм итә.

Урта һөнәри белем бирүче уку йортларында «Туган телдә әдәбият» дәресләрен укытканда түбәндәге методларны кулланырга була: дисскуссия, баш мие штурмы, эссе, синквейн, дидактик уеннар һәм башкалар. Аларның кайберләренә тукталып узарбыз.

Дискуссия методы студентларда үз фикерләрен белдерергә, аргументлар формалаштырырга, башкаларның фикерләрен тыңларга һәм анализларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, «Түгәрәк өстәл» барышында студентлар әсәрнең проблемалы мәсьәләләре турында фикер алышалар, төрле карашлар белән таныштыралар. «Герой өстеннән суд» формасында студентлар «адвокатлар» һәм «прокурорлар» га бүленеп, персонажларның гамәлләрен анализлый.

Уен ысуллары студентларны уку процессына ныграк җәлеп итүгә булыша, материалны мавыктыргыч һәм эмоциональ яктан баетылган итә. Әдәби викториналар һәм квестлар исә әсәрләр, авторлар, жанрлар турындагы белемнәрне уен рәвешендә ныгытырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, студентлар, билгеле авторларның стиленә охшатып, үз текстларын тудыра алалар.

Проектлар методы студентларга темаларны мөстәкыйль тикшерергә, мәгълүмат эзләргә, үз эшләренең нәтиҗәләрен докладлар, презентацияләр, видеороликлар рәвешендә күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Төркем белән эш методлары студентларның үзара хезмәттәшлек итү күнекмәләрен үстерүгә, фикер алышуга, мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә ярдәм итә. Мәсәлән, һәр төркем әсәрнең билгеле бер аспектын (сюжет, геройлар, символика) анализлый һәм үз нәтиҗәләрен тәкъдим итә. «Ми штурмы» идеяләрне генерацияләргә, гипотезалар формалаштырырга, проблемалы мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Заманча технологияләр интерактив белем бирү мөмкинлекләрен тагын да киңәйтә. Цифрлы проектлар (блоглар, подкастлар, видеопрезентацияләр) булдыру студентларның иҗади сәләтен үстерә. Укытучы исә интерактив укытуда белем бирү процессын оештыручы функциясен үти, студентларның эшчәнлеген оештыра, мәгълүматны мөстәкыйль эзләүгә этәреп, актив хезмәттәшлек өчен шартлар тудыра.

Дәресләрдә интерактив ысуллар куллану барышында иҗади фикерле һәм төрле ситуацияләрне чишүнең рациональ юлларын таба белгән студент киләчәк тормышта да югалып калмый. Шулай итеп, урта һөнәри белем бирү оешмасында әдәбият дәресләрендә интерактив методлар куллану нәтиҗәле алым булып тора.

Кулланылган әдәбият

1. Селевко Г.К. Энциклопедия образовательных технологий. М.: НИИ школьных технологий, 2006. 816 с.
2. Беспалько В.П. Педагогика и прогрессивные технологии обучения. М., 2010. 287 с.
3. Даутова О.Б., Крылова О.Н. Педагогические технологии для старшей школы в условиях цифровизации современного образования: учебно-методическое пособие для учителей. СПб.: КАРО, 2020. 176 с.

References

1. Selevko GK. *Ehntsiklopediya obrazovatel'nykh tekhnologii*=Encyclopedia of Educational Technologies. Moscow: Research Institute of School Technologies; 2006. 816 p. (In Russ.).
2. Bespal'ko VP. *Pedagogika i progressivnye tekhnologii obucheniya=Pedagogy and Progressive Teaching Technologies*. Moscow, 2010. 287 p. (In Russ.).
3. Dautova OB, Krylova ON. *Pedagogicheskie tekhnologii dlya starshei shkoly v usloviyakh tsifrovizatsii sovremennogo obrazovaniya: uchebno-metodicheskoe posobie dlya uchitelei=Pedagogical Technologies for High School in the Context of Digitalization of Modern Education: A Teaching Manual for Teachers*. St. Petersburg: KARO, 2020. 176 p. (In Russ.).